**СОВЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422602 с.Ташкирмень,
ул. Мира, д.40
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25
e-mail: Makar.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАКАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422602 Ташкирмән авылы,
Тынычлык урамы, 40 нчы йорт
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25
e-mail: Makar.La@tatar.ru

**2024 елның 29 марты** **198 номер**

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 14 декабрендәге 86 номерлы Макаровка авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (20.11.2023 елгы 177 номерлы карарлар редакциясендә)**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Макаровка авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 17 декабрендәге 52 номерлы Макаровка авыл җирлеге советы карарына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 12 статьяның 3 абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясындагы 7 пунктының 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш.".

«3_1. Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына, шәһәр округының генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.".

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Макаровка**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **В.В.Кормачев**